Шәһәр күләмендә Татар халкы һәм Татарстан тарихы фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
10-11 нче сыйныф

Эш вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 53

Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз.

1. 1917 елның апрелендә мөселман социалистик комитетының (МСК) башлыгы булып кем билгеләнә? (1 балл)

А) И.С. Алкин Б) М.Х. Солтангалиев В) Г. Исхакый Г) М. Вахитов

Җавап: _____

2. 1920 елның 27 маенда: (1 балл)

А) Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасына В.И. Ленин ордены бирелә;
Б) ТАССРның эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларының I оештыру съезды булып уза;
В) ТАССР төзелү турындагы декрет кабул ителә;
Г) ТАССРның вакытлы революцион комитеты (Татревком) оеша.

Җавап:_____

3. Татарстан АССР Югары Советы Президиумының татар язуын латин алфавитыннан кириллица нигезендәге алфавитка күчерү турындагы Указ кайчан кабул ителә? (1 балл)

А) 1918 ел Б) 1929 ел В) 1937 ел Г) 1939 ел

Җавап: _____

4. Татар мәдәнияте өлкәсендә аерым уңышлар өчен бирелә торган Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе ничәнче елда булдырыла? (1 балл)

А) 1948 елда Б) 1958 елда В) 1968 елда Г) 1998 елда

Җавап: _____

5. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасында «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында Шартнамә»гә кайчан кул куела? (1 балл)

А) 1994 елның 15 февралендә Б) 1990 елның 30 августында
В) 2000 елның 6 ноябрендә Г) 2005 елның 12 июнендә

Җавап: _____

6. Казан дәүләт университетының 200 еллыгы кайчан билгеләп үтелә? (1 балл)

А) 2000 елда Б) 2002 елда В) 2004 елда Г) 2006 елда Д) 2010 елда

Җавап:_____

7. 2005 елның 26 августында Казанның 1000 еллыгына багышланган паркта кемгә һәйкәл куела? (1 балл)

А) Федор Шаляпин Б) Габдулла Тукай В) Лев Толстой
Г) Кол Гали Д) Сәлих Сәйдәшев

Җавап: _____

8. Кайсы музей Казан Кремле музейлары комплексына карамый? (1 балл):

А) «Эрмитаж – Казан» үзәге;
Б) «Хәзинә» милли сәнгать галереясы;
В) Бакый Урманче музее;
Г) Ислам мәдәнияте музее;
Д) 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы;
Е) Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее

Җавап: _____

9. 1996 елда Казанда Дәүләт Зур концерт залы төзелә. 2000 елда аңа кемнең исеме бирелә? (1 балл.)

А) Габдулла Тукай Б) Сәлих Сәйдәшев В) Василий Качалов
Г) Муса Җәлил Д) Федор Шаляпин

Җавап: _____

10. Казан метрополитенының биш станциядән торган беренче линиясе кайчан ачыла? (1 балл)

А) 2000, 1 сентябрь Б) 2005, 4 ноябрь В) 2015, 9 июнь
Г) 2005, 27 август Д) 2010, 10 март

Җавап: _____

11. Сезнең алдыгызда ТАССР шагыйрьләре һәм язучылары исемлеге. Шулар арасыннан Бөек Ватан сугышында катнашкан өч әдипне күрсәтегез. (һәрбер дөрес җавап өчен – 2 балл, иң югары – 6 балл)

А) Ф. Кәрим Б) А. Гыйләҗев В) А. Расих Г) Г. Паушкин Д) Г. Ахунов

Җавап: _____

12. ТАССРда Бөек Ватан сугышы елларына караган вакыйгаларны даталары белән туры китерегез. (һәрбер дөрес җавап өчен – 2 балл, иң югары – 8 балл)

Дата	Вакыйга
А) 1941, июль	1) СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы оештырылу
Б) 1942, июнь	2) Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы каршында Эвакуация советы төзелү
В) 1944, 24 гыйнвар	3) Казанда Идел буе һәм Кама яны ресурсларын оборона ихтыяҗларына мобилизацияләү комиссиясе оештырылу
Г) 1945, апрель	4) Казан мех комбинатының Ленин ордены белән бүләкләнүе

Җавап:

А	Б	В	Г

13. Даталарны һәм вакыйгаларны туры китерегез. (һәрбер дөрес җавап өчен – 2 балл, иң югары – 10 балл)

Дата	Вакыйга
А) 2005 ел	1) Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасын уздыру
Б) 2013, 6–17 июль	2) Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү
В) 1992, 6 ноябрь	3) ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
Г) 2020 ел	4) Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итү
Д) 1990, 30 август	5) Татарстан Совет Социалистик Республикасы суверенитеты турында Декларация кабул итү

Җавап:

А	Б	В	Г	Д

14. Вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз: (тулы дөрес җавап өчен 5 балл)

А) Татар язуын гарәп графикасыннан яңалифкә (латиницага) күчерү;
Б) «Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы турында» Декрет кабул итү;
В) СССР Фәннәр Академиясы Казан филиалының ачылуы;
Г) Татар язуын латин графикасыннан кириллицага күчерү;
Д) композиторлар С. Габәши, В. Виноградов, Г. Әлмөхәммәтовның «Сания» дип аталган беренче татар операсының куелышы.

Җавап: _____

15. Түбәндәге текстны игътибар белән укыгыз. Сорауларга җавап бирегез. (иң югары – 4 балл)

1941 елда ТАССР территориясендә бу корылманы төзүдә 32 меңгә якын кеше катнаша. Бу эшкә колхозчылар, эшчеләр, интеллигенция, хуҗабикәләр, студентлар, өлкән сыйныф укучылары җәлеп ителә. Мобилизацияләнүчеләрнең дүрттән өч өлешен хатын-кызлар тәшкил итә. Эш авыр шартларда бара, яңгыр туктамый явып тора. Аннан кинәт 30 градуслы салкыннар башлана. Җир

ката. Җиңел киенгән төзүчеләрнең көрәк, авыр чүкеч һәм ломнары гына була. Транспорт чарасы – атлар. Әмма ачлык-ялангачлыкка, суыкның үзәккә үтүенә карамастан, 4 ай эчендә 330 чакрымга сузылган танкка каршы окоп казыла.

Текстта нинди корылманың төзелүе турында сүз бара? Ул ничек атала? (2 балл)
Ул нинди максат белән төзелгән? (2 балл)
Җавап: _____
_____

16. Фоторәсемдә кем сурәтләнгән? Әлеге шәхеснең тормыш юлы һәм иҗаты турында белгәннәрегезне языгыз. (Кем сурәтләнгән – 1 балл, һәрбер биографик факт өчен – 1 балл; иң югары – 10 б.)

Җавап:_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!